**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге гражданнар җыены карары (КАРАР)**

от «11» ноябрь 2019 г. № 1

**Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге составына керүче
Омар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында»гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 ст., Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар авылында 2019 елның 11 ноябрь узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Омар авылы Яшьләр урамы, Приречная урамы (сатып алу, ташу, вак таш җәю, грейдлау, килешү буенча эш өчен түләү;);

- Омар авылында юлларны кардан чистарту;

- Омар авылында һәйкәлне ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

« ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 267 кеше кертелгән;

халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 141 кеше;

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» 140 кеше тавыш бирде;

«Юк» 1 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар авылында узган халык җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Омар авылы Яшьләр урамы, Приречная урамы (сатып алу, ташу, вак таш җәю, грейдлау, килешү буенча эш өчен түләү;);

- Омар авылында юлларны кардан чистарту;

- Омар авылында һәйкәлне ремонтлау (материаллар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге
Советы рәисе ____________ Л.Н.Хәбибуллин